**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ИСКЕ МАТАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**ДЕПУТАТЛАР СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

**2014 елның 15 май** **96№**

**Иске Матак авыл җирлеге**
**җирләренән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен**
**раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, муниципаль берәмлекнең тотрыклы үсеше, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклап калу өчен шартлар тудыру, муниципаль берәмлек территориясен планлаштыру өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, шул исәптән җир кишәрлекләреннән, капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән төрләрен һәм объектларын сайлау мөмкинлеге бирү юлы белән, шулай ук гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Иске Матак авыл җирлеге депутатлары советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Матак авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренең тәкъдим ителгән проектын үзгәрешсез һәм өстәмәләрсез расларга.

2. Әлеге карар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районының
Иске Матак авыл җирлеге башлыгы: Г.В.Нагорнов